# Бөркет турында баллада

*Илдар Юзеев сүзләре*






1970

Хәбәр булып килде болыт,
Кояш нурын каплады.
Давыл узды, оя тузды —
Бөркет дустын тапмады.
Ә баласы, күз карасы
Сизмәде дә яшенне.
Ике канат канап-канап,
Зилзиләдән яшерде.

Очты бөркет, төште бөркет.
Йөрәгендә — ярасы.
Яшь аралаш елмая ул.
Югарыда — баласы.
Ә баласы, күз карасы
Сизмәде дә яшенне.
Ике канат канап-канап,
Зилзиләдән яшерде.